ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 май 2026 ел № 4554

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның керемнең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, 2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең максималь күләме – 60 967 сум 33 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 279 826 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 4 559 652 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 6 839 478 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 9 119 304 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 11 399 130 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 13 678 956 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 15 958 782 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 18 238 608 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми

бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов